5.8.1. — Общая педагогика, история педагогики и образования
**Ссылка для цитирования:**
Һадиева Г. В. Татар теле дәресләрендә уку грамоталылыгы формалаштыру — функциональ грамоталылыкның нигезе // Современное образование: актуальные вопросы и инновации. 2026. № 3 (30).
URL: https://irortsmi.ru/wp-content/uploads/2026/10/2026_3_khadieva.pdf

УДК 372.881.1

**Гөлнара Васил кызы Һадиева**
өлкән укытучы, Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты, Казан, Рәсәй

## Татар теле дәресләрендә уку грамоталылыгы формалаштыру — функциональ грамоталылыкның нигезе

***Аннотация.*** Мәкаләдә укучыларның уку грамоталылыгын формалаштыруда туган тел (татар) дәресләренең потенциалы карала. Татар текстларының үзенчәлеге телгә өйрәтү процессын лингвистик бурычтан тәнкыйди фикерләүне үстерү коралына әвереләдерә. Татар теле дәресләре милли тәңгәллекне саклау чарасы буларак кына түгел, ә аңлап укуның универсаль күнекмәләрен ныгыту өчен җирлек буларак та бирелә.
***Терәк сүзләр:*** функциональ грамоталылык, уку, уку грамоталылыгы, мәгълүмат, универсаль күнекмәләр, тәнкыйди фикерләү

**Gul'nara V. Khadieva**
Senior Lecturer, Institute for the Development of Education of the Republic of Tatarstan, Kazan, Russia

## FORMATION OF EDUCATIONAL LITERACY IN TATAR LANGUAGE LESSONS IS THE BASIS OF FUNCTIONAL LITERACY

***Abstract.*** The article examines the potential of native (Tatar) language lessons in the formation of functional reading literacy of schoolchildren. The specificity of Tatar texts transforms the language learning process from a linguistic task into a tool for developing critical thinking. Tatar language lessons are presented not just as a means of preserving identity, but as a platform for training universal skills of meaningful reading.
***Keywords***: functional literacy, reading, reading literacy, information, universal skills, critical thinking

Бүгенге көндә мәгариф системасында функциональ грамоталылык термины аеруча актив кулланыла. Нәкъ менә белем бирү системасының укучыларда функциональ грамоталылыкны формалаштыру һәм үстерү осталыгы аның глобаль конкурентлыкка сәләтен билгели. Функциональ грамоталылык — ул алынган белемне таныш булмаган тормыш ситуацияләрендә куллана алу сәләте. Аның төп күрсәткече — укучының язма мәгълүматка мөстәкыйль анализ ясавы һәм үз гамәлләрен аңлап башкаруы.

Функциональ грамоталылык системасында уку грамоталылыгы аерым урын алып тора. Хәзерге белем алу киңлегендә бу төшенчә уку техникасыннан шактый ерак тора. Ул текстны механик рәвештә укуны түгел, ә аннан кирәкле фрагментны табып, аны шәхси яки социаль бурычны хәл итү өчен файдалануны күздә тота. Тел дәресләре моның өчен уникаль шартлар тудыра.

Мәктәптә белем бирү контекстында метапредметлыкка ия булган уку грамоталылыгы барлык уку дисциплиналарын үзләштерү

© Һадиева Г. В., 2026

процессында формалаша торган предмет компетенцияләрен үстерүгә ярдәм итә. Уку грамоталылыгын формалаштыру һәм камилләштерү һәрбер предмет кысаларында өзлексез алып барылырга тиеш [1].

Туган тел дәресләрендә укытучы ике процесс – телне үзләштерү һәм текст белән эшләүнең универсаль күнекмәсен үстерү өстендә эшли. Татар теле дәресе лингвистик дисциплинадан дөньяны танып белү аша тирәнтен уку мәдәниятен формалаштыру өчен мөмкинлек бирә. Әлеге максаттан чыгып, белем һәм тәрбия бирү процессында төрле характердагы текстларны (әдәби, фәнни-популяр һ.б.) куллану нәтиҗәле була.

Уку грамоталылыгына ия булган кеше текстны пассив кабул итүне актив диалогка әйләндерә: ул автор белән аргументлы бәхәсләшә ала, фактологикраслауларны эмоциональ бәяләүдән һәм манипуляция алымнарыннан аера, ә иң мөһиме – укыганын стандарт булмаган тормыш мәсьәләләрен чишү, үз-үзен үстерү һәм уңышлы социаль коммуникация өчен ышанычлы корал буларак файдалана.

Уку грамоталылыгының нигезендә мәгълүмат белән эшли белү осталыгы ята. PISA Халыкара тикшеренүләре нигезендә, мәгълүмат белән эшләүнең өч база дәрәҗәсе бар [2]:

1) кирәкле мәгълүматны эзләп табу: җавап булган текст фрагментын эзләү; мәгълүматның булу-булмавын билгеләү; тоташ, тоташ булмаган (таблица, графика) һәм катнаш текстлардан мәгълүмат ала белү сәләте;

2) интеграция һәм интерпретация: текст өлешләре арасындагы бәйләнешне аңлау; подтекстны ачыклау; яшерен бәйләнешләрне (сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре) билгели белү; нәтиҗәләрне формалаштыра белү; визуаль һәм вербаль компонентларның үзара бәйләү;

3) аңлау һәм бәяләү: мәгълүматның дөреслеген, автор аргументларын, тел чараларының стилен һәм урынлы куллану дәрәҗәсен бәяләү; каршылыкларны ачыклау; үз фикереңне әйтә белү; укылганны үз тәҗрибәң белән чагыштыра белү; автор позициясенә тәнкыйди карау.

Татар теле һәм әдәбияты укытучысы текст белән эшләүне оештырганда 3 дәрәҗәне дә үз эченә алган бирем-сораулар тәкъдим итәргә тиеш. Бары тик шул очракта гына текст өстендә комплекслы эш оештыру турында сөйләргә була. Практика күрсәткәнчә, еш кына сораулар яки биремнәр мәгълүматны табу гына кайтып кала.

Татар теле дәресе кысаларында уку грамоталылыгы формалаштырганда микротекстларны аналитик укуга басым ясала. Укучылар деформацияле текстлар (җөмләләр тәртибен торгызу) белән эшлиләр, җөмләләр арасындагы бәйләү чараларын билгелиләр, сөйләмдә функциональ стильләренең лексик һәм грамматик үзенчәлекләрен коммуникатив нәтиҗәлелеге аша анализлый.

Уку грамоталылыгын үстерү укы һәм сөйлә форматындагы фронталь сораштыруга гына кайтып калырга тиеш түгел. Бу эш проблемалы сораулар һәм продуктив биремнәр тирәсендә оештырыла. Укучыларда уку грамоталылыгын тиешле дәрәҗәдә формалаштыру максатыннан тормыш белән бәйле стандарт булмаган биремнәр тәкъдим итәргә кирәк. Мондый төрдәге биремнәрне үтәү, кагыйдә буларак, белемнәрне таныш булмаган ситуациядә куллану, эш-гамәлләрнең һәм проблеманы чишү юлының яңа ысулларын эзләүне күз алдында тота. Дәресләрдә түбәндәге алымнарга тукталу отышлы булачак.

1. «Вакыйгалар картасы» урынына менталь карта төзү

Укучылардан Роберт Миңнуллин яки Ләбиб Лерон шигырьләренең эчтәлеген сорау кирәк түгел. Алардан шагыйрьнең лирик героеның психологик халәтен визуаль схема ярдәмендә күрсәтүләрен сорарга кирәк. Бу схемада эпитетлар, метафоралар да билгеләнә. Нәтиҗәдә укучы текстны эчтән «тарата», аның структурасына төшенә. Бу исә дәрестә формалаштыра торган мәгълүмат эшкәртү күнекмәсен турыдан-туры тормыш контекстына күчерергә ярдәм итә.

2. Тукталышлар белән уку

Текст (Абдулла Алиш әсәреннән өзекме яки Казан зоопаркы турында мәкаләме) мәгънәви өлешләргә бүленә. Һәр өлештән соң укытучы сюжетны аңлауга түгел, ә фикерләүгә һәм алга таба фаразлауга сораулар бирә («Сез ничек уйлыйсыз, ни өчен герой нәкъ шулай эшләгән? Әгәр без бу сүзне синонимы белән алыштырсак, нәрсә үзгәрер иде?»). Әлеге алым текстның эзлеклегенә игътибар итәргә өйрәтә.

3. Креоллаштырылган текстлар белән эшләү

Хәзерге дөнья мемнар, слоган, реклама һәм социаль челтәрләрдәге кыска постлар телендә сөйләшә. Татар теле дәресләрендә вербаль өлеш визуаль образлар белән ярашкан текстларны куллану нәтиҗәле булачак. Әлеге максаттан чыгып, мәсәлән, татар телендәге реклама шигарен, «Сабантуй» журналы тышлыгын яки популяр татар төркеме видеоклибын анализлау белән бәйле эш төрләрен тәкъдим итү отышлы була. Укучылар язылганның мәгънәсенә сурәтнең ничек тәэсир иткәнен билгеләргә тиеш: тулыландырамы, дөрес күрсәтәме, автор нинди манипулятив алымнар кулланган?

4. Жанр трансформациясе

Текстны ни дәрәҗәдә аңлауны тикшерүнең иң нәтиҗәле ысулларының берсе — текстның асылын саклап калып, аның формасын үзгәртеп карау. Мәсәлән, Хәсән Туфан поэмасыннан өзекне яшьләр аудиториясе өчен подкаст сценарийсына әйләндереп язу. Яки, киресенчә, вакыйганың коры тасвирламасын эмоциональ көндәлек өзегенә үзгәртүне сорарга мөмкин. Бу исә мәгънәнең лексика дәрәҗәдә генә түгел, ә структура дәрәҗәсендә дә үзләштерелүен исбатлый.

Әлбәттә, уку грамоталылыгын формалаштыру барышында төрле кыенлыклар да килеп туарга мөмкин. Бу хаталар текст белән эшләү күнекмәләрен үстерүне тоткарлап кына калмыйлар, шулай ук, татар әдәбияты белән кызыксынуны да киметәләр. Укытучы эш барышында барлыкка килгән хаталарның характерын билгеләп, алга таба аларны булдырмау юлларын эзләргә тиеш.

Уку грамоталылыгы формалаштыру барышында барлыкка килгән типик хаталар һәм аларны булдырмау ысуллары:

1. Анализ урынына эчтәлекне сөйләү. Еш кына укучы сорауга эчтәлектән өзек белән җавап бирә. Бу очракта түбәндәгечә эшләп була: укучылар текст буенча сорауларга тулы җөмләләр белән җавап биргәндә алардан җавапны үзгәртеп әйтүне таләп итү кирәк. Теләсә нинди сорауга җавапны «Мин ... дип саныйм» яки «Автор ... күрсәтергә теләгән» кебек клишелардан башларга өйрәтергә кирәк.

2. Төрле мәгънә белдергән охшаш сүзләрне игътибарсыз уку һәм текстны дөрес аңламау. Сүзләрнең мәгънәсен дөрес аңламау замана проблемасына әйләнеп бара. Укучыга контекстта башка мәгънә төсмергә ия булган сүзләрнең исемлеген алып барырга яки сүзлек төзергә тәкъдим итәргә була.

3. Классик әдәбиятка гына игътибар итү. Текст белән эшләү күнекмәләрен формалаштыруны басма әдәбият кысаларында гына карау мәгълүмат белән эшләүнең бер генә юнәлешен чагылдыра. Проблеманың чишелеше түбәндәгечә булырга мөмкин: дәрес эчтәлеген актуаль материаллар — интернет челтәрендәге видео астындагы шәрехләр яки сериалларга субтитрлар белән тулыландыру. XXI гасыр грамоталылыгы цифрлы тирәлектә дә ориентлашуны таләп итә.

Туган тел (татар) дәресләрендә уку грамоталылыгын формалаштыру методик бурыч кына түгел, ә укучыларда милли мәдәниятне саклау һәм тәнкыйди фикерләвен үстерү өчен нигез булып тора. Функциональ грамоталылыкка ия булган укучы мәгълүмат дөньясында ориентлашырга, манипуляцияләрдән сакланырга һәм үз фикерен матур, ышанычлы итеп җиткерергә өйрәнә. Туган тел дәресе нәкъ менә шундый күнекмәләр формалаштыру өчен җирлеккә әйләнергә тиеш.

Әдәбият

1. Добротина И.Н. Читательская грамотность школьника. М.: Вентана-Граф, 2018. 144 с.
2. Гончарук С.Ю. Русский язык. Сборник задач по формированию читательской грамотности. 8–11 классы. М.: Просвещение, 2020. 208 с.

References

1. Dobrotina IN. *Chitatel'skaya gramotnost' shkol'nika* = *The student's reading literacy.* Moscow: Ventana-Graf, 2018. 144 p. (In Russ.)
2. Goncharuk SY. *Russkiy yazyk. Sbornik zadach po formirovaniyu chitatel'skoy gramotnosti* = *Russian language. Collection of tasks for the formation of reading literacy. Grades 8–11*. Moscow: Prosveshchenie Publ., 2020. 208 p. (In Russ.)